

Гадәт буенча, элек-электән мәктәп укучылары тирә-кvршедә яшәгән олыларга ярдәм кvрсәтәләр. Шуна торле акцияләр, агымнар уйлап табалар. Безнен чакларда «Тимурчылар» агымы дип атала иде. Волонтерлар ел буе ярдәмнәре белән олыларнын кvнелләрен кvтәрәләр.
Торбеево укучылары «Жылы тәрәзә-ләр» акциясе кысаларында сугыш һәм хезмәт ветераннарына, инвалидларга һәм карт кешеләргә, бер сvз белән әйткәндә, ярдәмгә мохтажларга, кулларыннан килгәнчә булышалар. Торбеево олылары малайларны һәм кызларны, кадерле кунаклары тосле, котеп алалар. Алар йорт жирләрендә тәртип урнаштыралар, идәннәрен юалар, тә-рәзәләрен кышка тиешле материал белән сылап жылыталар. Бар эшкә дә житешәләр бу балалар. Шулай, бу коннәрдә генә хезмәт ветераннарынын - 96 яшьлек Татьяна апа Кашкарованын һәм 83 яшьлек Наталья апа Глухованын тәрәзәләрен кәгазь белән сылап чыкканнар, ә Рәйсә апа Мансурованын оен жыештырганнар, идәннәрен дә юып алганнар.



Кадошкино районы Большие Поляныда «Ихлас кvнелдән» дигән волонтерлар акциясе кысаларында олы яшьтәге авыл халкына укучылар шулай ук ярдәм кvрсәтә. Бу программа кысаларында утызлап Боек Ватан сугышы, тыл һәм хезмәт ветеранына ярдәм кvрсәткәннәр инде. Бер акция белән генә чикләнми алар; ел буе шулай ярдәм итәләр. Волонтерлар белән картлар очен «Хезмәт десанты», «Унышлы бакча», «Чиста ой» дигән акцияләр оештырыла һәм vткәрелә. Зур уныш алган акцияләр арасында «Ветераннарыбыз янәшәбездә яши» һәм «Кvнел жылысы» дигәннәре популяр. Бу чаралар vткәргән вакытта Большеполяны топ мәктәбе укучылары олыларны, торле

бәйрәмнәр белән котлап, vз куллары белән эшләнгән бvләкләрен дә оләшәләр. Бу бер конлек ярдәм тvгел, авылда акциясез дә әби-бабайларга хужалыкларында ярдәм итәләр: су алып керәләр, йорт тирәсен жыештыралар, жәйләрен бакчаларында яшелчәләр vстерергә ярдәм итәләр, ә козләрен – унышларын жыешалар; пресса яналыклары белән таныштыралар.
Шундый очрашулар эзсез vтми; олылар тормыш тәжрибәләре белән уртаклашалар, биографияләре белән таныштыралар, милли мәдәният, традицияләр турында сойлиләр һәм һәрвакыт рәхмәтлеләр.

**Наилә Насырова**